| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

05.08.2024 — № 647-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 августындагы 1051-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 августындагы 1051-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләре кертергә:

**1.1.** 1.1. пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.1 Әлеге нигезләмә эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен кирәгеннән артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган актлар проектында эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының, Саба муниципаль районы бюджетының нигезләнмәгән чыгымнарын барлыкка китерүче нигезләмәләрне ачыклау максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары

проектларының (алга таба - актлар проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү тәртибен (алга таба - норматив хокукый актлар) билгели.».

**2.** Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә игълан итәргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе М.Р. Ишниязов